**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел.(85552) 3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail:mail.Aktanish@tatar.ru ,www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
26. 0 3. 2020

КАРАР
№ ПР-59

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә югары әзерлек режимын кертү турында**

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә яңа короновирус инфекциясе (2019-nCoV) таралу куркынычы янауга бәйле рәвештә, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында" 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законның 4[1] статьясындагы 6 пунктының "б" пунктчасы нигезендә, Россия Федерациясе Президентының 2020 елның 25 мартындагы 206 номерлы Указын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 25 мартындагы 218 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Түбәндәгеләрне билгеләргә:

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә 20 һәм аннан да күбрәк кеше булган спорт, тамаша кылу, ачык һәм башка чаралар уздыру рөхсәт ителми.

2. 2020 елның 26 мартыннан Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы территориясендә түбәндәгеләрне туктатып торырга:

- спорт үзәкләре, йөзү бассейннары, кинозаллар, дискотекалар, балалар өчен уен бүлмәләре һәм башка күңел ачу оешмалары эшчәнлеген;
- ресторannнар, кафелар, буфетлар, барлар, кабымлыклар һәм башка җәмәгать туклануы оешмалары, гражданнарның үзләре кермичә, ризыкны чыгарып бирүгә көйләнгән , шулай ук заказлар китерүче оешмалардан тыш;
- ваклап сату объектларының, аптека һәм дарухanә пунктларыннан тыш, шулай ук беренче чиратта кирәк булган ваклап сату объектларының азык-төлек товарларын сату өлешендә, товарларны дистанцион ысул белән сату, шул исәптән илтеп җиткерү шарты белән;
-матурлык, косметика, СПА-салоннары, массаж салоннары, солярий, мунча, сауна һәм башка объектларның гражданның турыдан-туры катнашуын күздә тоткан эшләре.

3. Гражданнарга дини объектларга йөрүдән тыелырга киңәш итәргә.
4. 2020 елның 26 мартыннан 15 апреленә кадәр 65 яшьтән өлкәнрәк яшьтәге гражданнар үз-үзләрен изоляцияләү режимын сакларга.
5. «Татмедиа» ААҖ филиалы "Актаныш мәгълүмат - мөхәррият үзәге" директорына ММЧ да яктыртырга:

- яңа коронавирус йогышын профилактикалау буенча тәкъдимнәр (2019-nCoV);

торган йогышлы чир таралуга китерә торган гамәл кылу/гамәл кылмау өчен җаваплылык турында кисәтү.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча : http://pravo.tatarstan.ru -Актаныш муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И.Габдулхаев